Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Сизнер торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 2

13 ноябрь, 2024 ел.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сизнер авылы торак пунктында гражданнар җыены карар бирә:

1. Балтач районының Сизнер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салым акчасын 600 сум күләмендә кертергә. Балачактан инвалидларга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләргә, ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерларга, Россия армиясендәге гражданнарга, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 95% күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентларга 50% күләмендә ташламалар ясарга.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Смәел авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Йосыпов